ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.03.2026 Мөслим № 97

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының«Өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның балаларын мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Мөслим муниципаль районы мәгариф оешмаларында карап торган һәм караган өчен түләүдән азат итү турында» 2022елның 14 ноябрендәге 660 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә,«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2026 елның 26 февралендәге 377/26 номерлы «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 елның 09 ноябрендәге 1903/22 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында»,МХОдә катнашучыларга ярдәм чараларын күрсәтү өчен типлаштырылган болытлы чишелешне кертү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгының 2025 елның 01 декабрендәге 1000пр номерлы киңәшмәсе протоколы нигезендә,Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының «Өлешчә мобилизация кысаларында хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның балаларын мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Мөслим муниципаль районы мәгариф оешмаларында карап торган һәм караган өчен түләүдән азат итү турында» 2022елның 14 ноябрендәге 660 номерлы карарының 2 пунктына үзгәреш кертергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2.1. Социаль ярдәм чараларын электрон форматта тәкъдим итү;

2.2. Өстенлекле ярдәм чараларына карата социаль ярдәм чараларын проактив форматта тәкъдим итү;

2.3. Әгәр белешмәләр Россия Оборона министрлыгы мәгълүматлары витринасында ачык булса, хәрби комиссариатның ата-анасын (законлы вәкилен) мәгариф оешмасына чакыру турындагы белешмәсе нигезендә, кәгазь документ таләпләрен төшереп калдыру.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм ТР Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет

җитәкчесенең социаль-мәдәни үсеш буенча урынбасары М. Р. Бәдретдиновага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф.Салихҗанов**